КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Республиканское агентство по печати
и массовым коммуникациям
Декабристов ул., 2, г.Казань, 420066

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
Республика матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр агентлыгы
Декабристлар ур., 2, Казан шәһәре, 420066

Тел.: (843)570-31-22, факс:(843)537-91-04, ra.tatmedia@tatar.ru, tatmedia.tatarstan.ru

ПРИКАЗ БОЕРЫК

19.08.2025 № 123-п

«Террорчылыкка каршы торуны Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы яктыртуга конкурс үткәрү турында» «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2021 елның 2 июнендәге 82-п номерлы боерыгы белән расланган Террорчылыкка каршы торуны Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы яктыртуга конкурс үткәрү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 16 октябрендәге 764 номерлы карары белән расланган «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» Татарстан Республикасы дәүләт программасының «Террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау» процесс чаралары комплексын гамәлгә ашыру кысаларында БОЕРЫК БИРӘМ:

«Террорчылыкка каршы торуны Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы яктыртуга конкурс үткәрү турында» «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2021 елның 2 июнендәге 82-п номерлы боерыгы белән расланган Террорчылыкка каршы торуны Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы яктыртуга конкурс үткәрү турында нигезләмәгә («Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2024 елның 16 августындагы 169-п номерлы боерыгын исәпкә алып), аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

Житәкче А.С. Сәлимгәрәев

“Татмедиа” республика матбугат һәм
массакүләм коммуникацияләр агентлыгының
2021 елның «___» ___________
____ номерлы боерыгы белән
РАСЛАНДЫ

Террорчылыкка каршы торуны
Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында
иң яхшы яктыртуга конкурс үткәрү турында
НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 16 октябрендәге 764 номерлы карары белән расланган «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» Татарстан Республикасы дәүләт программасының «Террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау» процесс чаралары комплексын гамәлгә ашыру кысаларында Террорчылыкка каршы торуны Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы яктыртуга конкурс (алга таба – Конкурс) оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели.

1.2. Конкурсның оештыручысы – “Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы (алга таба – Агентлык);

1.3. Конкурс ел саен 30 декабрьгә кадәр үткәрелә.

«Конкурсны үткәрү турындагы мәгълүмат Агентлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://tatmedia.tatarstan.ru) (алга таба – Агентлыкның рәсми сайты) “Яңалыклар”, “Конкурслар һәм проектлар” бүлекләрендә урнаштырыла. Конкурс үткәрү турындагы мәгълүматта Конкурсны үткәрү шартлары, номинацияләр, конкурс эшләр бәяләү критерийлары һәм тәртибе, гаризалар кабул ителү урыны, сроклары, гаризалар кабул ителә башлау һәм төгәлләнү вакыты, аларны тапшыру тәртибе, бүләкләү күләме һәм рәвешләре, шулай ук Конкурс нәтиҗәләрен игълан итү тәртибе күрсәтелә.

1.4. Конкурста җиңүчеләргә дипломнар һәм акчалата бүләкләр тапшырыла.

## 2. Конкурсның максатлары һәм бурычлары

2.1. Конкурсның максаты:

Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чаралары һәм блогерлар игътибарын җәмгыятькә яный торган террорчылык мәсьәләләренә (шул исәптән АУЕ-хәрәкәтләр, дини экстремистлык, деструктив төркемнәр, девиант холык) юнәлтү;

террорчылыкка һәм экстремистлыкка каршы торуда ММЧ социаль ролен һәм абруен күтәрү.

2.2. Конкурсның төп бурычлары:

ММЧ вәкилләрен һәм блогерларны террорчылыкка каршы контент (басма, аудиовизуаль, электрон) булдыруга җәлеп итү;

журналистларга һәм блогерларга җәмгыятьтә террорчылык һәм экстремистлык идеологиясе чагылышларына түзеп торалмаучанлык формалаштыруда ярдәм итү.

## 3. Нигезләмәдә кулланыла торган төп төшенчәләр

3.1. Гариза бирүче – әлеге Нигезләмәнең 5 бүлеге нигезендә гариза тапшырган авторлар, авторлар коллективлары яисә ММЧ буларак теркәлгән редакцияләр, блогерлар (алга таба – гариза тапшыручылар).

3.2. Блог – эчтәлеге Татарстан Республикасы дәүләт телләрен саклауга һәм популярлаштыруга юнәлдерелгән текст, сурәт яисә мультимедиа рәвешендә даими өстәлеп торучы язмалардан гыйбарәт вакыйгалар интернет журналы, социаль челтәрләрдә аккаунт яисә төркем, мессенджерларда һәм видеохостингларда канал;

Блоглар даирәсе – бергәлек яисә социаль челтәр буларак, барлык блоглар җыелмасы;

3.3. Катнашучы – эшләре Конкурста катнашырга рөхсәт ителгән гариза тапшыручылар (алга таба – катнашучылар).

3.4. Конкурс комиссиясе – Конкурска тәкъдим иткән эшләрне бәяләүче затлар төркеме.

3.5. Конкурста җиңүче – призлы урын алган катнашучы.

## 4. Конкурста катнашучылар

4.1 Конкурста Агентлыкның рәсми сайтында күрсәтелгән срокларда гариза тапшырган авторлар, авторлар коллективлары яисә ММЧ буларак теркәлгән редакцияләр, блогерлар катнаша;

4.2. Гариза бирүче Конкурсның бер номинациясендә катнашу өчен бер генә гариза бирә ала.

4.3 Конкурска гариза бирүче берничә номинация буенча документлар тапшыра ала, бу очракта жюри тарафыннан карала торган документлар һәрбер номинация буенча аерым әзерләнергә тиеш. Бер үк конкурс эше Конкурсның төрле номинацияләренә бирелә алмый.

## 5. Конкурсны үткәрү шартлары

5.1. Конкурс номинацияләре нигезендә гариза бирүчеләр тарафыннан конкурска түбәндәге эшләр тапшырыла:

массакүләм мәгълүмат чараларында узган Конкурска йомгак ясау вакытыннан алып чираттагы Конкурска гаризалар кабул итү тәмамланганчы басылып чыккан материаллар;

социаль челтәрләрдә, мессенджерларда һәм видеохостингларда ("Террорчылыкка каршы иң яхшы контент өчен" блогерлар өчен махсус номинациядә) рәсми аккаунтларда (шәхси блогларда) узган Конкурска йомгак ясау вакытыннан алып чираттагы Конкурска гаризалар кабул итү тәмамланганчы басылып чыккан материаллар.

5.2. Конкурска түбәндәге документларны кабул итә:

а) конкурс эшләре:

саклау ресурсына сылтама рәвешендә телевизион эшләр (программалар, махсус репортажлар, видеосюжетлар циклы, документаль фильм). Конкурс эшләренә эшнең исеме, авторлары һәм эфирга чыгу датасы күрсәтелгән эфир белешмәсе кушып бирелә. Әлеге белешмә массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе җитәкчесе имзасы һәм мөһере (булган очракта) белән таныкланган булырга тиеш;

анкетада күрсәтелгән саклау ресурсына сылтама рәвешендә басма массакүләм мәгълүмат чараларындагы язмалар (язмалар сериясе, махсус чыгарылышлар). Язмалар массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе җитәкчесе имзасы һәм мөһере (булган очракта) белән таныкланган булырга тиеш;

анкетада адреслы сылтама күрсәтелеп, интернет басмалардагы язмалар;

саклау ресурсына сылтама рәвешендә радиоэшләр (программалар, махсус репортажлар, радиосюжетлар циклы). Конкурс эшләренә эшнең исеме, авторлары һәм эфирга чыгу датасы күрсәтелгән эфир белешмәсе кушып бирелә. Әлеге белешмә массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе җитәкчесе имзасы һәм мөһере (булган очракта) белән таныкланган булырга тиеш;

анкетада адреслы сылтама күрсәтелеп, блоклар (социаль челтәрләрдә, мессенджерларда һәм видеохостингларда рәсми аккаунтларда террорчылыкка һәм экстремистлыкка каршы фикер тудыруга юнәлдерелгән постлар);

б) катнашу өчен Анкета-гариза (1 нче кушымта);

в) юридик зат буларак теркәлгән массакүләм мәгълүмат чарасы редакцияләре өчен:

юридик затны салым органында исәпкә кую турында таныклык (ИНН);

юридик зат җитәкчесен вазыйфага билгеләп кую турында боерык;

гамәлгә кую документлары;

массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклык йә теркәлгән массакүләм мәгълүмат чаралары реестрыннан өземтә;

г) юридик зат булмаган массакүләм мәгълүмат чарасы редакцияләре өчен:

массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклык йә теркәлгән массакүләм мәгълүмат чаралары реестрыннан өземтә;

массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе уставы яисә, массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясендә иң күбе 10 кеше эшләсә, “Массакүләм мәгълүмат чаралары турында” 1991 елның 27 декабрендәге 2124-I номерлы Россия

Федерациясе Законының (алга таба – ММЧ турында Закон) 20 статьясы нигезендә аны алмаштыра торган шартнамә;

д) физик затлар (авторлар, авторлар коллективлары, блогерлр) өчен:

шәхесне таныклый торган документ;

әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымта нигезендә Персональ белешмәләрне эшкәртүгә, тапшыруга имза куеп ризалык бирү;

персональ белешмәләр субъекты рөхсәт иткән персональ белешмәләрне таратуга имза куеп ризалык бирү (3 нче кушымта);

е) уртак эш тапшыра торган авторлар, блогерлар, авторлар коллективлары һәм ММЧ редакцияләре өчен:

конкурс эшенә призлы урын бирелгән очракта акчаны процентлап бүлешү турында имза куеп килешү.

Әлеге пунктның «а» пунктчасында күрсәтелгән эфир белешмәләре һәм басма ММЧ язмалар, әлеге пунктның «б» - «е» пунктчаларында күрсәтелгән документлар, кәгазь документларның электрон рәвешләре буларак, ачык форматта, гамәлдәге программалар белән тәэмин ителгән җайланмалар аша тулысынча яки аерым өлешләрен карау мөмкинлеге булган килеш, «Террорчылыкка каршы торуны Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы яктыртуга конкурска» дигән тамга белән konkurs_zozh@mail.ru электрон почта адресына җибәрелә. Бу абзацта күрсәтелгән документлар шифр ярдәмендә яисә эчтәлек белән танышу өчен лицензияле яки башка килешү төзеп, сатып алына торган өстәмә программалар таләп ителә торган башка чаралар ярдәмендә сакланган булырга тиеш түгел. Белешмәләр өчен телефон: 8 (843) 570-31-04.

5.3. Конкурс эшләре Россия Федерациясе дәүләт телендә, Россия Федерациясе составындагы республикаларның дәүләт телләрендә, Россия Федерациясендәге башка халыклар телләрендә тапшырыла. Россия Федерациясе составындагы республикаларның дәүләт телләрендә, Россия Федерациясендәге башка халыклар телләрендә тапшырылган эшләрнең русчага тәрҗемәсе бирелә. Ул массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе җитәкчесе имзасы һәм мөһере (булган очракта) белән таныкланган булырга тиеш.

5.4. Конкурска килгән эшләргә рецензия бирелми. Анкета Конкурс үткәрү турында хәбәр белән бергә Агентлыкның рәсми сайтында «Яңалыклар», «Конкурслар һәм проектлар» бүлекләренә урнаштырыла.

5.5. Документларның Агентлыкка килгән көне аларны тапшыру датасы дип санала.

5.6. Конкурста катнашуга рөхсәт бирмәү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

гаризаның әлеге Нигезләмәнең 5.1. – 5.3. пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яисә гаризага әлеге Нигезләмәнең 5.2. пунктында каралган документларны теркәмәү (барысын да теркәмәү);

конкурста катнашу өчен гаризаны билгеләнгән срокны бозып тапшыру;

сурәтендә яисә тавышында хилафлыклар булган эшләр тәкъдим итү;

гариза бирүченең әлеге Нигезләмәнең 3.1, 3.3 пунктларында каралган затлар категориясенә кермәве;

гариза бирүченең 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты статусына ия булуы (авторлар коллективы әгъзасы (лары) «Чит ил йогынтысындагы затларның эшчәнлеген тикшереп тору турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил статусына ия булган очракта, чит ил агенты (лары) дип танылган заттан кала, авторлар коллективына рөхсәт ителә);

тапшырылган конкурс эшенең конкурс һәм (яисә) номинация темасына туры килмәве.

5.7. Катнашучыга Конкурска кертелмәү турында хәбәр документларны алган көннән алып биш эш көне эчендә, Оештыручы җитәкчесе (җитәкче урынбасары) имзалаган һәм анкета-гаризада күрсәтелгән адреска җибәрелгән заказлы хат белән хәбәр ителә.

5.8. Конкурста катнашуга кертелмәгән эшләр Агентлыкның рәсми сайтында урнаштырылган срокларда төзәтелгән очракта яңадан тапшырылырга мөмкин.

5.9. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (почта, командировка чыгымнары һ.б) гариза бирүчеләр/катнашучылар тарафыннан мөстәкыйль түләнә.

5.10. Гариза бирүчеләр интеллектуаль милек объектларына барлык хокукларның бары тик Гариза бирүчеләрнеке булуын һәм Агентлык тарафыннан алардан файдалануның интеллектуаль милек турындагы Россия Федерациясе законнарын һәм / яисә өченче затларның хокукларын бозмауны гарантияли.

Конкурста катнашуга гариза биреп, Гариза бирүче Агентлыкның конкурс эшләрендә булган интеллектуаль милек объектларыннан конкурска бәйле максатларда файдалануына ризалыгын белдерә.

Тапшырылган материалга (гаризага) карата өченче затларның нинди дә булса дәгъвалары барлыкка килгән очракта, Гариза бирүче Агентлыкны җәлеп итмичә генә аларны тулы күләмдә (турыдан-туры һәм башка зыяннарны каплауны да кертеп) җайга салырга тиешАгентлык эшләрне, шул исәптән бүләкләргә лаек булган эшләрне дә киләчәктә файдалануны күздә тотмый, шуңа бәйле рәвештә Конкурста катнашучылар эшләрне киләчәктә ничек файдалануны мөстәкыйль хәл итә.

5.11. Конкурста җиңүчеләрне бүләкләү датасы һәм урыны Агентлыкның рәсми сайтында өстәмә хәбәр ителә.

## 6. Конкурсның номинацияләре

6.1. Конкурс түбәндәге номинацияләрдә үткәрелә:

«Террорчылыкка каршы тору темасын массакүләм мәгълүмат чараларында оригиналь яктырткан өчен» (1, 2, 3 урын);

«Массакүләм мәгълүмат чараларында террорчылыкка каршы тору темасына багышланган иң яхшы аналитик материал» (1, 2, 3 урын);

«Террорчылыкка каршы иң яхшы контент» (1, 2, 3 урын);

## 7. Конкурс эшләрен бәяләү критерийлары

7.1. Конкурс эшләрен бәяләү критерийлары:

эчтәлекнең Конкурс тематикасын чагылдыруы, аналитика (0-5 балл);

һөнәрилек дәрәҗәсе (тамашачылар тарафыннан җиңел кабул ителү, сурәтләү чаралары куллану) (0-5 балл);

Татарстан Республикасы халкы өчен тәрбияви һәм иҗтимагый кыйммәте булу (0-5 балл);

концепциянең, сценарийның һәм билгеләнгән тематиканы яктыртуның кабатланмаган булуы (0-5 балл).

7.2. Конкурс комиссиясе гомуми баллны конкурс эшләренә комиссиянең барлык әгъзалары куйган бәядән чыгып билгели.

## 8. Конкурс комиссиясен оештыру һәм аның эшчәнлек тәртибе

8.1. Конкурс комиссиясенең составы Агентлык боерыгы белән 8 кешедән раслана һәм рәистән, рәисе урынбасарыннан, комиссия әгъзаларыннан тора.

8.2. Конкурс комиссиясе үз эшен түләүсез башкара.

8.3. Конкурс комиссиясе эше утырышларда гамәлгә ашырыла. Утырышта конкурс комиссиясе әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, утырыш тулы хокуклы дип таныла.

8.4. Конкурс комиссиясе эшенә рәис җитәкчелек итә. Комиссия рәисе булмаганда, рәис вазыйфалары рәисе урынбасарына йөкләнә.

8.5. Әлеге Нигезләмәнең 7 бүлегендә билгеләнгән критерийлар нигезендә конкурс комиссиясе әгъзалары конкурс эшенә бәя бирә. Һәрбер эш буенча баллар саны 5 баллы шкала буенча билгеләнә (0 – 5 балл).

8.6. Һәрбер критерий буенча баллар суммасы нигезендә конкурс комиссиясе һәрбер номинация буенча катнашучыларның рейтингын билгели. Рейтинг нигезендә җиңүчеләр билгеләнә.

8.7. Бер номинациягә бер генә гариза тапшырылса, бер гариза да тапшырылмаса, тапшырылган гаризаларның берсе дә конкурс шартларына туры килмәсә, катнашкан эшләрнең берсе дә билгеләп үтәргә лаек дип танылмаса, Конкурс бу номинациядә үткәрелмәгән дип таныла һәм акчалар башка номинациядә билгеләнгән җиңүчеләр арасында тигез итеп бүленә.

Нинди дә булса номинациядә бирелгән яисә катнашуга кертелгән гаризалар саны җитәрлек булмау сәбәпле призлы урын бирелмәгән очракта, бу призлы урын өчен билгеләнгән акчалар башка номинациядә билгеләнгән җиңүчеләр арасында тигез итеп бүленә.

8.8. Баллар саны тигез булганда, номинациядә призлы урын конкурс комиссиясе тарафыннан ике яки берничә катнашучыга бирелә. Бу очракта тиешле призлы урын өчен каралган акчалар Конкурсны оештыручы тарафыннан җиңүчеләр арасында тигез өлешләрдә бүленә.

8.9. Җиңгән эш берничә авторныкы (физик затлар өчен)/берничә ММЧ (юридик затлар өчен) булса, номинациянең әлеге урыны өчен тәгаенләнгән акчалар җиңүчеләр арасында гариза тапшырганда бирелгән килешү нигезендә бүленә.

8.10. Оештыру-техник эшчәнлекне координацияләү, утырышларны әзерләү һәм документларны алып бару өчен конкурс комиссиясе рәисе җаваплы секретарь билгели.

8.11. Җаваплы секретарь конкурс комиссиясе составына керми һәм утырышларда тавыш бирү хокукыннан башка гына катнаша.

8.12. Җаваплы секретарь Конкурс комиссиясе утырышы уздырылган көннән алып биш эш көне эчендә Конкурс комиссиясе утырышы йомгаклары буенча беркетмә рәсмиләштерә, аңа утырышта булган конкурс комиссиясе әгъзаларының имзасы салына, беркетмә конкурс комиссиясе рәисе яисә рәисе урынбасары тарафыннан раслана.

## 9. Финанс белән тәэмин итү

9.1. Конкурс «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 16 октябрендәге 764 номерлы карары белән расланган «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» Татарстан Республикасы дәүләт программасының «Террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау» процесс чаралары комплексын гамәлгә ашыру кысаларында Террорчылыкка каршы торуны Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы яктыртуга оештырыла торган конкурсны үткәрү өчен Агентлыкка Татарстан Республикасы бюджетыннан тиешле финанс елына бүлеп бирелгән акчалар исәбенә финанслана.

9.2. Гомуми приз фонды 300 000 сум тәшкил итә.

9.3. Конкурста җиңүчеләр түбәндәге тәртиптә бүләкләнә:

| № | Номинация | Урын | Сумма (меӊ сум) |
|---|---|---|---|
| 1 | «Террорчылыкка каршы тору темасын массакүләм мәгълүмат чараларында оригиналь яктырткан өчен» | 1 урын | 45,0 |
| | | 2 урын | 30,0 |
| | | 3 урын | 20,0 |
| 2 | «Массакүләм мәгълүмат чараларында террорчылыкка каршы тору темасына багышланган иң яхшы аналитик материал» | 1 урын | 35,0 |
| | | 2 урын | 25,0 |
| | | 3 урын | 15,0 |
| 3 | «Террорчылыкка каршы иң яхшы контент» махсус номинация | 1 урын | 40,0 |
| | | 2 урын | 30,0 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | 3 урын | 20,0 |

9.4. Юридик затларга акча беркетмәгә имза салган мизгелдән алып 20 көн дәвамында беркетмә нигезендә аларның исәп-хисап счетына күчерү юлы белән түләнә.

9.5. Физик затларга акча беркетмәгә имза салган мизгелдән алып 20 көн дәвамында беркетмә нигезендә аларның банк счетына күчерү юлы белән түләнә яисә Агентлыкның финанс бүлегендә кулларына тапшырыла.

## 10. Аерым шартлар

10.1. Оештыручылар түбәндәгеләргә хокуклы:

әлеге Нигезләмәдә һәм Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында билгеләнгән очраклардан, шулай ук бәхәсле очраклардан тыш, Конкурста катнашучылар белән язмача йә башка төрле элемтәләргә кермәскә;

эшләрне тапшыру срогының беренче яртысында Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәп, Конкурсны туктатырга, бу хакта Агентлыкның рәсми сайтында (http://tatmedia.tatarstan.ru) “Яңалыклар” бүлегендә тиешле мәгълүмат урнаштырып, Катнашучыларга хәбәр итәргә.

10.2. Конкурс шартлары үзгәрү турында хәбәрнамә алганнан соң, Конкурста катнашучы эшләрне элек билгеләнгән шартларда кабул итүне яисә кертелгән үзгәрешләрне гамәлдә түгел дип тануны таләп итә алмый. Аның эшне Конкурсның яңа шартларына туры китереп үзгәртүе алга таба конкурста катнашырга мөмкинлек бирә.

10.3. Конкурста катнашырга рөхсәт ителгәннән соң «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген тикшереп тору турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты дип танылган катнашучы чәчәкләр, диплом һәм акчалата премия белән бүләкләнми.

Конкурста катнашырга рөхсәт ителгәннән соң составында «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген тикшереп тору турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты дип танылган зат (-лар) булган авторлар коллективы чәчәкләр, диплом һәм акчалата премия белән бүләкләнми.

«Террорчылыкка каршы торуны
Татарстан Республикасы массакүләм
мәгълүмат чараларында
иң яхшы яктыртуга конкурс турында
нигезләмәгә
1 нче кушымта

| Конкурста катнашу өчен анкета-гариза | |
|---|---|
| Гариза бирүче (ММЧ, автор, авторлар коллективы) | |
| Номинация | |
| Конкурс эше | |
| Кыскача эчтәлек | |
| Саклау ресурсына сылтама | |
| Адрес | |
| Телефон | |
| Электрон почта | |
| Гариза бирүченең банк реквизитлары (банк исеме, банкның БИК, ИНН, КПП белешмәләре, исәп-хисап счёты): | |
| ИНН (физик затлар өчен) | |
| СНИЛС (физик затлар өчен) | |

Террорчылыкка каршы торуны Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы яктыртуга конкурска тәкъдим ителгән эшләр өченче затларның авторлык һәм башка хокукларын бозмый;

«Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген тикшереп тору турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-Ф номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормыйм;

авторлар коллективы әгъзалары арасында «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген тикшереп тору турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып танылган затлар юк.*.

ММЧ редакциясе җитәкчесе (журналист) исем-фамилиясе, атасының исеме_____________________________________________________________

(җитәкче/ физик зат имзасы, мөһер (булган очракта)

* Гариза бирүче авторлар коллективы булса күрсәтелә

Дата _________________

Имза _____________________ ____________________________

(фамилия )

«Террорчылыкка каршы торуны Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы яктыртуга конкурс турында нигезләмәгә

2 нче кушымта

**Персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалык**

Мин,________________________________________________________,

яшәү адресым____________________________________________,

шәхесне таныклаучы төп документым (паспорт)_____________________

_______________________________________________________________________,

“Персональ белешмәләр турында” 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә “Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына (алга таба – оператор) (адресы: 420097, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 йорт) Террорчылыкка каршы торуны Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы яктыртуга конкурста катнашуга бәйле рәвештә үземнең персональ белешмәләрне эшкәртүгә, аларны җыюны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, төгәлләштерүне (яңартуны, үзгәртүне), алардан файдалануны, аларны таратуны (шул исәптән башкаларга тапшыруны), үз исемемнән башка файдалануны, блокировать итүне, юкка чыгаруны да кертеп, ризалыгымны бирәм.

Эшкәртүгә ризалыгымны бирә торган персональ белешмәләрнең исемлеге:

| | |
|---|---|
| Эшкәртүгә ризалыгымны бирә торган персональ белешмәләрнең исемлеге: | (фамилия, исем, атасы исеме, җенес, туган көн һәм урын, гражданлык, шәхесне таныклаучы документның реквизитлары (документ төре, сериясе һәм номеры, кем тарафыннан бирелүе), яшәү урыны, теркәлү урыны, телефон номеры (шул исәптән кәрәзле телефон), электрон почта адресы, Россия Федерациясе кредит оешмасында ачылган исәп-хисап счеты турында белешмәләр) |

Әлеге ризалык имзаланган көннән алып 1 (бер) ел гамәлдә була.

Персональ белешмәләрнең субъекты үз персональ белешмәләрен эшкәртүгә әлеге ризалыкны, бу хакта операторга язмача хәбәр итеп, кире алырга хокуклы.

Персональ белешмәләрнең субъекты үз персональ белешмәләрен эшкәртүгә әлеге ризалыкны кире алган очракта оператор аларны эшкәртүне туктатырга яисә туктатуны тәэмин итәргә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) һәм, персональ белешмәләрне эшкәртү өчен аларны саклау башкача кирәк булмаса, ризалыкны кире алу турында мөрәҗәгать кергән көннән алып утыз көн эчендә персональ белешмәләрне юкка чыгарырга яисә юкка чыгаруны тәэмин итәргә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) тиеш. Күрсәтелгән вакыт эчендә персональ белешмәләрне юкка чыгару мөмкинлеге булмаган очракта, оператор аларны блокировать итә яисә блокировать итүне тәэмин итә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) һәм персональ белешмәләрне иң күп дигәндә алты ай эчендә юкка чыгара.

_______________________________________________________________/__________

(персональ белешмәләр субъектының Ф.И.Ат ис. һәм имза)».

«Террорчылыкка каршы торуны
Татарстан Республикасы
массакүләм мәгълүмат
чараларында иң яхшы яктыртуга
конкурс турында нигезләмәгә

3 нче кушымта

**Тарату өчен персональ белешмәләр субъекты тарафыннан рөхсәт ителгән персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалык**

Мин, ________________________________________________________________,

(фамилия, исем, атасының исеме (булган очракта) рус телендә)

________________________________________________________________________,

(почта адресы)

_____________________________________________________,

(электрон почта адресы)

________________________________________________________________________,

(телефон номеры)

“Персональ белешмәләр турында” 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 10[1] статьясы нигезендә “Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына (ОГРН 1031621014765, ОКТМО 92701000, ОКПО 14912163) юридик адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 йорт) Террорчылыкка каршы торуны Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы яктыртуга конкурста катнашуга бәйле рәвештә үземнең персональ белешмәләрне таратуга (шул исәптән башкаларга тапшыруга, бирүгә) ризалыгымны бирәм.

Эшкәртүгә ризалык бирелә торган персональ белешмәләрнең категориясе һәм исемлеге

| N т/с | Персональ белешмәләр | Ризалык | |
|---|---|---|---|
| | | Әйе | ЮК |
| Гомуми персональ белешмәләр | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Фамилия | | |
| | Исем | | |
| | Атасы исеме (булган очракта) | | |
| | Җенес | | |
| | Гражданлык | | |
| | Туган ел, ай, дата һәм урын | | |
| | Шәхесне таныклаучы документның реквизитлары (төре, сериясе, датасы, кем тарафыннан бирелүе) | | |
| | Яшәү урыны, теркәлү урыны | | |
| | Телефон | | |
| | Электрон почта адресы | | |
| | Россия Федерациясе кредит оешмасында ачылган счет турында белешмәләр | | |
| | ИНН | | |
| | СНИЛС | | |

Эшкәртү өчен шартлар һәм тыю билгеләнә торган персональ белешмәләрнең категориясе һәм исемлеге

| N т/с | Персональ белешмәләр | Билгеләнә торган шартлар һәм тыюлар исемлеге |
|---|---|---|
| 1. [Персональ белешмәләрнең категориясе] | | |
| | [Персональ белешмәләрнең исемлеге] | |

Искәрмә. Күрсәтелгән таблица персональ белешмәләр субъектының теләге буенча, персональ белешмәләрне эшкәртүне гамәлгә ашыра торган оператор тарафыннан чикләүләрсез тутырыла.

Шартлар һәм тыюлар операторның чикләнмәгән яисә кайбер даирә затларына әлеге персональ белешмәләрне таратуга һәм (яисә) тапшыруга бәйле гамәлләрен чикләүне йә тыюны күздә тота.

Ризалыкта өстәмә шартлар да күрсәтелергә мөмкин, алар алынган персональ белешмәләрне эшкәртүне гамәлгә ашыра торган оператор тарафыннан мәгълүмат кайбер хезмәткәрләргә генә җиткерелә торган эчке элемтәләр буенча йә мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша тапшыруны, яки алынган персональ белешмәләрне тапшырмауны күздә тота

Операторның персональ белешмәләр субъектының персональ белешмәләре чикләнмәгән яисә кайбер даирә затларына тапшырылырга мөмкин мәгълүмат ресурслары турында белешмәләр: http://tatmedia.tatarstan.ru/.

Әлеге ризалык ______________________________ срокта гамәлдә була.

**(ризалыкның гамәлдә булу срогы)**

Персональ белешмәләр субъекты, операторга язмача хәбәр итеп, үзенең персональ белешмәләрен эшкәртүгә бирелгән ризалыктан баш тартырга хокуклы.

Персональ белешмәләр субъекты, операторга язмача хәбәр итеп, үзенең персональ белешмәләрен эшкәртүгә бирелгән ризалыктан баш тарткан очракта оператор мондый баш тартуны алган көннән алып иң күбе утыз көн эчендә аларны эшкәртүне туктатырга яисә туктатуны тәэмин итәргә (әгәр бу эш оператор кушуы буенча башка зат тарафыннан башкарылса) һәм, элек куелган максатлар өчен персональ белешмәләрне эшкәртү башкача таләп ителмәсә, персональ белешмәләрне юкка чыгарырга яисә юкка чыгаруны тәэмин итәргә (әгәр бу эш оператор кушуы буенча башка зат тарафыннан башкарылса) тиеш.

Күрсәтелгән срокта персональ белешмәләрне юкка чыгару мөмкинлеге булмаган очракта, оператор мондый персональ белешмәләрне блокировать итә яисә блокировать итүне тәэмин итә (әгәр бу эш оператор кушуы буенча башка зат тарафыннан башкарылса) һәм персональ белешмәләрне алты айдан артмаган срокта юкка чыгаруны тәэмин итә.

_______________(персональ белешмәләр субъекты имзасы)

_______________ (число, ай, ел)».